# Татарстан мөселманнарының 8-нче корылтае

Әссәламәгәләйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтух.

Хөрмәтле авылдашлар!

2021 елның 12 апрелендә Казан шәһәрендә 8-нче Татарстан мөселманнарының корылтае узды. Корылтайда Татарстанның барлык районнарыннан, шәһәрләреннән имам-мөхтәсиблар, имам-хатыйблар катнашты. Шулай ук корылтайда зур кунак Татарстан Президенты Нургали улы Рөстәм Миннеханов та катнашты. Корылтайны баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев ачып җибәрде. Килгән кунакларны һәм корылтай делегатларын Р.Н.Миннеханов котлады.

Корылтай түбәндәге сорауларны карады:

1. Татарстан Диния нәзарәте мөфтиенең отчеты;
2. Татарстан Диния нәзарәте мөфтиен яңа срокка сайлау;
3. Татарстанның Диния нәзарәтенең баш казыен сайлау;
4. Татарстан Диния нәзарәтенең ревизия комиссиясен сайлау;
5. Башка сораулар;
6. Дин әһелләрен, имам- мөхтәсибләрне, имам-хатыйбларны бүләкләү.

Корылтай Диния нәзарәт мөфтие Камиль хәзрәт Самигуллинның отчетын тыңлагач, аны алдагы срокка мөфтий итеп сайлады. Баш казый итеп Җәлил хәзрәт Фазлыев сайланды.

Соңыннан бер төркем дин әһелләренә төрле бүләкләр тапшырдылар.

*Мехаматнур хәзрәт Нәҗметдинов, 13 апрель, 2021 ел*

*Бүләкләнүчеләр арасында Бәзәкә авыл мәчете имам-хатыйбы Мехаматнур хәзрәт Нәҗметдинов та бар: ул Татарстан Республикасы Диния нәзарәтенең “Бердәмлек” медале кавалеры булды. Бөтен авыл халкы исеменнән Мехаматнур хәзрәтне шул югары бүләге белән котлыйбыз һәм аңа алдагы эшләрендә дә яңа уңышлар, ныклы сәламтәтлек телибез!*




*Менделеевск районы вәкилләрре.*
*Сулдан уңга: имам-нәиб Раиль хәзрәт (Менделеевск), имам-нәиб Айрат хәзрәт (Тойма),*
*имам-нәиб Мансур хәзрәт (Песәй), имам-хатыйб Рәшит хәзрәт (Абалач),*
*хаҗи Мәгъсүм хәзрәт (Турай), имам-мөхтәсиб Ирек хәзрәт (Менделеевск),*
*имам-хатыйб Флур хәзрәт (Турай), имам-нәиб Наиль хәзрәт (Менделеевск),*
*имам-хатыйб Мехаматнур хәзрәт (Бәзәкә),имам-нәиб Алмаз хәзрәт (Ахтиял),*
*имам-нәиб Фидаиль хәзрәт (Ижевка)*


Республика
Татарстан
VIII
ТАТАРСТАН
МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ
КОРЫЛТАЕ
Kazan Expo


VIII
ТАТАРСТАН


VIII
ТАТАРСТАН
МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ
КОРЫЛТАЕ